**РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ**

**ФЕДЕРАЛЬ КАНУН**

# ЯТИМ БАЛАЛАРНЫ ҺӘМ АТА-АНА ТӘРБИЯСЕННӘН МӘХРҮМ КАЛГАН БАЛАЛАРНЫ, ЯТИМ БАЛАЛАР ҺӘМ АТА-АНА ТӘРБИЯСЕННӘН МӘХРҮМ КАЛГАН БАЛАЛАР САНЫННАН БУЛГАН ЗАТЛАРНЫ ТОРАК УРЫННАРЫ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ӨЛЕШЕНДӘ РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ АЕРЫМ КАНУН АКТЛАРЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА

2018 елның 17 июлендә
Дәүләт Думасы тарафыннан
кабул ителгән

2018 елның 24 июлендә
Федерация Советы тарафыннан
хупланган

**Маддә 1**

1996 елның 21 декабреннән 159-ФЗ номерлы "Балаларга өстәмә ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында" Федераль канунның 8-нче маддәсенә (Рәсәй Федерациясе кануннары җыелышы, 1996, № 52, 5880; 1998, № 788; 2004, № 35, 3607 маддә, 2012, № 10, 1163 маддә, 2013, № 27, 3477 маддә; 2015, № 48, 6724 маддә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1-нче пунктта:

а) икенче абзацка "әлеге пунктның беренче абзацында" сүзләреннән соң "аларның язма гаризасы буенча" сүзләрен өстәргә;

б) өченче абзацта "сәламәтлек саклау системасы оешмалары һәм башка оешмалар" сүзләрен "медицина оешмалары һәм башка оешмалар" сүзләренә алмаштырырга, "һөнәри белем бирү" сүзләреннән соң "һөнәри уку" сүзләрен өстәргә;

2) 2-нче һәм 3-нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Рәсәй Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Рәсәй Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары яллаучылары яки социаль яллау килешүләре буенча яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар булган торак урыннарның куллануын һәм саклануын, торак урыннарның тиешле санитар һәм техник торышын тәэмин итүен, шулай ук аларның идарә итүен күзәтеп торырга тиеш.

3. Рәсәй Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы әлеге мадданең 1-нче пункты нигезендә торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлеген, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саныннан затлар исемлеген, мадданең 9-нчы пунктында күрсәтелгән затлар исемлеген (алга таба- "исемлек") төзи. Әлеге мадданең 1-нче пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән затлар исемлеккә 14 яшькә җиткәч кертелә.

Исемлекне формалаштыру тәртибе, исемлеккә кертү турында гариза формасы, исемлеккә кертү өчен кирәк булган документларның якынча исемлеге, исемлеккә кертү яки исемлеккә кертүне кире кагу турында карар кабул итү вакыты һәм нигезләре, шулай ук исемлеккә кертү вакыты Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Исемлеккә кертү турында гариза 14 яшькә җиткән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның канун тарафыннан каралган вәкилләре тарафыннан күрсәтелгән яшькә ирешүләре яисә әлеге мадданең 1 пунктындагы беренче абзацында каралган торак урыннар бирү нигезләре барлыкка килгән көненнән алып өч ай эчендә бирелә.

Опека һәм попечительлек органнары ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның канун тарафыннан каралган вәкилләре тарафыннан әлеге балаларны исемлеккә кертү турындагы гаризаларны үз вакытында тапшырылуын күзәтеп тора, һәм мондый гаризалар булмаган очракта әлеге балаларны исемлеккә кертү буенча чаралар

күрелә.

Балигъ булганчы тулы юридик хокукка ия булган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саныннан затлар, әгәр дә алар билгеләнгән тәртиптә балигъ булганчы йә тиешенчә 18 яше тулганчы тулы юридик хокукка ия булганчы исемлеккә кертелмәгән булсалар һәм торак урыннары белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашырмаган булсалар, мөстәкыйль рәвештә исемлеккә кертү турындагы язма гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.";

3) түбәндәге эчтәлекләргә 3.1-нче пунктын өстәргә:

"3.1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саныннан затлар исемлектән киләсе очракларда төшереп калдырыла:

1) әлеге матдәнең 1-нче пункты нигезендә аларга торак урыннары бирелгән очракта;

2) махсуслаштырылган торак урыннарын яллау килешүләре буенча махсуслаштырылган торак фондының төзекләндерелгән торак урыннарын бирү өчен әлеге маддә тарафыннан каралган нигезләрне югалткан очракта;

3) яшәү урыны үзгәрү сәбәпле аларны Рәсәй Федерациясенең башка субъектында исемлеккә керткән очракта. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саныннан затларны Рәсәй Федерациясе субъектында элеккечә яшәү урыны буенча исемлектән төшереп калдыру тәртибе һәм аларны Рәсәй Федерациясе субъектында яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

4) әгәр дә Рәсәй Федерациясенең халыкара килешүе белән башкасы каралмаган булса, аларның Рәсәй Федерациясе гражданнары булудан туктатуы очрагында;

5) үлем яки аларны Рәсәй Федерациясе кануннары белән билгеләнгән

тәртиптә үле дип белдерү очракларында.";

4) 4-нче пунктның 2-нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) торак биналар торак кануннары тарафыннан билгеләнгән нигезләр һәм тәртип буенча яшәү өчен яраксыз дип табылды;

5) 6-нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Әлеге маддәнең 1-нче пункты нигезендә бирелә торган махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүенең гамәлдә булу вакыты биш ел тәшкил итә.

Әлеге маддәнең 1-нче пунктында күрсәтелгән затларга авыр тормыш хәлен җиңеп чыгарга ярдәм итү кирәклеге турында таныклаучы шартлар ачыкланган очракта, махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе Рәсәй Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы карары буенча берничә тапкыр яңа биш еллык вакытка төзелергә мөмкин. Әлеге шартларны ачыклау тәртибе Рәсәй Федерациясе субъекты кануннары белән билгеләнә.

Махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүенең гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң һәм әлеге маддәнең 1-нче пунктында күрсәтелгән затларга авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм итү кирәклеге турында таныклаучы шартлар булмаган очракта, дәүләт торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Рәсәй Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы торак урынын махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турында карар кабул итәргә һәм әлеге маддәнең 1-нче пунктында күрсәтелгән затлар белән Рәсәй Федерациясе субъекты кануннары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әлеге торак урынына карата социаль яллау килешүен төзергә тиеш.";

6) 7-нче пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Әлеге маддәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларга фатирлар рәвешендә бирелә торган торак урыннарның бер күпфатирлы йортта гомуми саны Рәсәй Федерациясе субъекты кануннары тарафыннан билгеләнә һәм шул ук вакытта әлеге күпфатирлы йорттагы фатирларның гомуми саныннан 25 проценттан

артмаска тиеш.".

**Маддә 2.**

"Рәсәй Федерациясенең дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллек) һәм башкарма органнарын оештыру гомуми нигезләре турында" (Рәсәй Федерациясе кануннары җыелышы, 1999, № 42, 5005 маддә; 2003, № 27, 2709 маддә; 2005, № 1, 17, 25 маддәләр; 2006, № 1, 10 маддә; № 23, 2380 маддә; № 30, 3287 маддә; № 31, 3452 маддә; № 44, 4537 маддә; № 50, 5279 маддә; 2007, № 1, 21 маддәләр; № 13, 1464 маддә; № 21, 2455 маддә; № 30, 3747, 3805, 3808 маддәләр; № 43, 5084 маддә; № 46, 5553, 5556 маддәләр; 2008, № 29, 3418 маддә; № 30, 3613, 3616 маддәләр; № 48, 5516 маддә; № 52, 6236 маддә; 2009, № 48, 5711 маддә; № 51, 6163 маддә; 2010, № 15, 1736 маддә; № 31, 4160 маддә; № 41, 5190 маддә; № 46, 5918 маддә; № 47, 6030, 6031 маддәләр; № 49, 6409 маддә; № 52, 6984 маддә; 2011, № 17, 2310 маддә; № 27, 3881 маддә; № 29, 4283 маддә; № 30, 4572, 4590, 4594 маддәләр; № 48, 6727, 6732 маддәләр; № 49, 7039, 7042 маддәләр; № 50, 7359 маддә; 2012, № 10, 1158, 1163 маддәләр; № 18, 2126 маддә; № 31, 4326 маддә; № 50, 6957, 6967 маддәләр; № 53, 7596 маддә; 2013, № 14, 1663 маддә; № 19, 2331 маддә; № 23, 2875, 2876, 2878 маддәләр; № 27, 3470, 3477 маддәләр; № 40, 5034 маддә; № 43, 5454 маддә; № 48, 6165 маддә; № 51, 6679, 6691 маддәләр; № 52, 6981, 7010 маддәләр; 2014, № 11, 1093 маддә; № 14, 1562 маддә; № 22, 2770 маддә; № 26, 3371 маддә; № 30, 4256, 4257 маддәләр; № 42, 5615 маддә; № 43, 5799 маддә; № 45, 6138 маддә; 2015, № 1, 11 маддә; № 13, 1807, 1808 маддәләр; № 27, 3947 маддә; № 29, 4359 маддә; № 41, 5628 маддә; 2016, № 23, 3283 маддә; № 26, 3866 маддә; № 27, 4222 маддә; 2017, № 1, 6 маддә; № 31, 4828 маддә; № 45, 6573 маддә; № 50, 7563 маддә; 2018, № 1, 26, 27, 87 маддәләр; № 7, 972, 975 маддәләр; № 17, 2425 маддә; № 24, 3414 маддә) 1999 елның 6 октябреннән 184-ФЗ номерлы Федераль канунның 26.3 маддәсенең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14.3 пуктчасын өстәргә:

"14.3) яллаучылары яки социаль яллау килешүләре буенча яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре ятим балалар һәм ата-ана

тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар булган торак биналарның куллануын һәм саклануын, торак урыннарының тиешле санитар һәм техник торышын тәэмин итүен, шулай ук аларның идарә итүен күзәтеп тору".

**Маддә 3**

Рәсәй Федерациясенең Торак кодексына (Рәсәй Федерациясе канунчылыгы җыелмасы, 2005, № 1, 14 маддә; 2012, № 10, 1163 маддә; № 31, 4322 маддә; 2018, № 1, 72 маддә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 72-нче маддәнең 3-нче өлешендә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Социаль яллау килешүе буенча балигъ булмаган (балигъ булмаганнар) һәм әлеге балигъ булмаганнарга карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән гражданнар, балигъ булмаган (балигъ булмаганнар) белән бергә яшәүче башка затлар тарафыннан алып торган торак урынын мәҗбүри рәвештә алыштырырга кирәк булган очракта, әгәр дә шул гражданнарның әлеге балигъ булмаган балалар белән уртак яшәве балигъ булмаганнарның хокукларын һәм канунлы мәнфәгатьләрен бозса, балигъ булмаган балаларның канун тарафыннар каралган вәкилләр, опека һәм попечительлек органы яисә прокурор, судка тиешле таләп белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2) 90-нчы маддәдә:

а) "Әгәр дә яуллаучы" сүзләрен "1. Әгәр дә яллаучы" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2-нче өлеш өстәргә:

"2. Әгәр дә балаларның һәм аларга карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән гражданнарның уртак яшәүләре суд тарафыннан мөмкин түгел дип танылган икән, Рәсәй Федерациясе субъектының кануны тарафыннан әлеге гражданнар балигъ булмаган балаларның канун тарафыннан каралган вәкилләре, опека һәм попечительлек органы яки прокурор таләбе буенча суд тәртибендә башка торак урынына күчерелергә мөмкин, аның күләме гражданнарны тулай торакларга урнаштыру өчен билгеләнгән торак урыны күләменә туры килә.";

3) 91-нче маддәнең 2-нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Әгәр дә балаларның һәм аларга карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән гражданнарның уртак яшәүләре суд тарафыннан мөмкин түгел дип танылган икән, мондый гражданнар балигъ булмаган балаларның канун тарафыннан каралган вәкилләре, опека һәм попечительлек органы яки прокурор таләбе буенча, әгәр дә Рәсәй Федерациясе субъектының кануны белән башкасы каралмаган булса, суд тәртибендә башка торак урыны белән тәэмин ителмичә торак урыннан чыгарылырга мөмкин.";

4) 101-нче маддәдә:

а) 3-нче өлешкә "3. Махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе" сүзләреннән соң "әлеге Кодексның 98.1-нче маддәсендә каралган махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүеннән тыш" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 4-нче өлеш өстәргә:

"4. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар санынннан затлар өчен махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе яллаучы һәм аның белән яшәүче гаилә әгъзалары тарафыннан махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе буенча үз йөкләмәләрен үтәмәү сәбәпле, яллауга бирүче таләбе буенча суд тәртибендә өзелергә мөмкин, шулай ук киләсе очракта өзелергә мөмкин:

1) торак урыны һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен бер елдан артык түләүне яллаучы тарафыннан кертмәү һәм торак урыннарына һәм (яки) коммуналь хезмәтләргә түләү буенча барлыкка килгән бурычларны түләү буенча килешү булмаган очракта;

2) торак урынны яллаучы яки аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары тарафыннан җимергән яки даими зыян китергән очракта;

3) бер торак урында бергә яшәүне мөмкин түгел хәлгә җиткезеп, күршеләрнең хокукларын һәм канун тарафыннан каралган мәнфәгатьләрен даими рәвештә бозу очрагында;

4) торак урыннан билгеләнүеннән тыш файдалану";

5) 103-нче маддәсенең 5-нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саныннан затлар белән махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүен әлеге Кодексның 101-нче маддәсенең 4-нче өлеше тарафыннан каралган нигезләр буенча өзгән очракта, алар һәм алар белән торучы гаилә әгъзалары торак урыннан чыгарылырга һәм тиешле торак пункты чикләрендә махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе буенча торак урыны белән тәэмин ителергә тиеш, аның күләме гражданнарны тулай торакларга урнаштыру өчен билгеләнгән торак урыны күләменә туры килә.";

6) 109.1-нче маддәсенә түбәндәге эчтәлекле 3-нче һәм 4-нче өлешләрен өстәргә:

"3. Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саныннан затларга махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүе буенча бирелгән торак урыннарга аларның балигъ булмаган балалары һәм ире (хатыны) керә ала. Күрсәтелгән затлар махсуслаштырылган торак урынын яллау килешүенә кертелә.

4. Әлеге маддәнең 1-нче өлешендә күрсәтелгән затларның үлүе очрагында, дәүләт торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Рәсәй Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы торак урынын махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турында карар кабул итәргә һәм әлеге маддәнең 1-нче пунктында күрсәтелгән затлар белән Рәсәй Федерациясе субъекты кануннары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әлеге торак урынына карата социаль яллау килешүен төзергә тиеш.".

**Маддә 4**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә килешү системасы турында" 2013 елның 5 апреленнән 44-ФЗ номерлы Федераль канунга (Рәсәй Федерациясе кануннары җыелышы, 2013, № 14, 1652 маддә, № 52, 6961

мәддә, 2014, № 23, 2925 маддә, 2015, № 1, 51 маддә, 2016, № 27 4253, 4298 маддәләр; 2018, № 1, 88 маддә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 83-нче маддәнең 2-нче өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11-нче пункт өстәргә:

"11) Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар санышнан затлар өчен әлеге торак урыннарның милекчеләре булган физик затлардан торак урыннарын сатып алуны гамәлгә ашыру.";

2) 83.1-нче маддәнең 2-нче өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7-нче пункт өстәргә:

"7) Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар санышнан затлар өчен әлеге торак урыннарның милекчеләре булган физик затлардан торак урыннарын сатып алуны гамәлгә ашыру.".

**Маддә 5**

Әлеге Федераль канун 2019 елның 1-нче гыйнварыннан үз көченә керә.

**Рәсәй Федерациясе**

**Президенты**

**В.ПУТИН**

Мәскәү, Кремль

2018 елның 29 июле

№ 267-ФЗ